«Рассмотрено»
Руководитель МО

Хузина Р.М. _______
Протокол № 1
от «23» 08 2017 г.

«Согласовано»
Заместитель директора по УРВ ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»

_______ Яковлева М.В.

от «23» 08 2017 г.

«Утверждаю»
Директор
ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»

_______ Беспалова Т.В.
Приказ № 43
от «25» 08 2017 г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного предмета, курса, дисциплины (модуля)
ЧОУ «Академический Лицей им. Н.И. Лобачевского»

Шакировой Гульнары Расиховны, к.п.н.
Ф.И.О., категория

по татарской литературе, 7А класса
предмет, класс и т.п.

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1
от «23» 08 2017 г.

20 17 - 20 18 учебный год

# УЧЕБНО-ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ ПРАКТИЧЕСКОЙ ЧАСТИ УЧЕБНОЙ ПРОГРАММЫ ПО ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ

Класс: 7

Учитель: Шакирова Г.Р.

Количество часов: всего - 70 ;  в неделю – 2.

Плановых контрольных работ: 2.

Административных контрольных работ:  1.

## Аңлатма язуы

Татар әдәбиятыннан 7 нче сыйныф укучылары өчен төзелгән программа дәүләт стандартларының федераль компонентына, гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп эшләнгән Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисмәтова, Э.Х.Гыйзәтуллина, Г.Г.Мулласалихова тарафыннан язылган дәреслекләрдән (1 нче, 2 нче кисәк) укытуны күздә тота. Программа стандартның эчтәлеген җентекләп ачып бирә, стандарт таләп иткән күләмдә рус телле балаларга татар әдәбиятын укытуның гомуми юнәлешләрен билгели, предмет чаралары белән укучыларны тәрбияләү юлларын, аларның әдәби үсеш дәрәҗәсен билгели.

Күпмилләтле аудиториядә татар әдәбиятын укыту өчен төзелгән программа бербөтен документ булып тора, ул биш өлешне иңли: аңлатма язуы; укыту курсының эчтәлеге, укыту-тематик планы; укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр; курсның укыту-методик тәэмин ителеше өчен әдәбият исемлеге.

Әдәбият һәр яктан үскән, рухи яктан бай, әхлакый идеаллары һәм эстетик таләпләре булган камил шәхес тәрбияләүдә әһәмиятле урын алып тора. Урта белем бирү системасындагы татар әдәбияты курсы сәнгатьне тормыш белән бәйләп өйрәнүне, эчтәлек белән форма берлеге, тарихилык, традиция һәм новаторлык, тарихи-культурологик мәгълүматларны аңлау, әхлакый-эстетик күзаллау булдыру, әдәбият теориясе һәм тарихы буенча төшенчәләрне үзләштерү, әдәби әсәрне бәяләү күнекмәләрен формалаштыру, әдәби телнең сәнгатьлелек чаралары белән танышуны үз эченә ала.

Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән татар әдәбияты дәреслекләре барлык фәннәрне өйрәнү барышындагы фундаменталь төшкә (фундаментальное ядрога), универсаль уку гамәлләренә нигезләнә, укучыларның яшь һәм әдәби үсеш дәрәҗәсен исәпкә ала. Укыту һәм тәрбиянең гомуми нәтиҗәләре иҗтимагый, шәхси, танып-белү һәм коммуникатив үсешне тәэмин итеп, укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен үстереп, дөньяны танып белүгә әзерләп, хезмәттәшлеккә, үзлегеннән белем алуга, камиллеккә омтылучы шәхес тәрбияләүгә барып тоташа. Аерым алганда, уку-укытуга системалы-гамәли якын килү нәтиҗәсендә, укучыларның **иҗтимагый** үсешенә (халыкның рухи кыйммәтләрен аңлаучы, үстерүче Россия гражданины тәрбияләү); **шәхси** үсешенә (үзлегеннән белем алырга, иҗади сәләте үскән, компетентлы, үзаңы үскән, үзенең гражданлык карашларын ачыктан-ачык белдерүгә сәләтле, үз-үзенә тәнкыйди караштa торган, тормыш авырлыкларына каршы торырлык шәхес тәрбияләү); **танып белү** эшчәнлеген үстерүгә (фәнни дөнья сурәтен аңлаучы, үзенең танып-белү һәм интеллектуаль эшчәнлеге белән идарә итә ала торган, уку, белем алу чараларын күзаллый торган, репрезентатив, символик, логик, иҗади фикерләү сәләте үскән, рефлексиягә сәләтле укучы тәрбияләү); **коммуникатив** үсешкә (аралашу компетенциясе үскән, тыңларга, диалогта, гомуми сөйләшүдә катнаша алырлык, туган телен, рус телен, чит телне камил белүенә) басым ясалды. Шул ук гамәлләрне тормышка ашыру барышында, яшүсмерләрнең яшь үзенчәлекләре дә игътибарга алынды.

Күпмилләтле мохиттә гомуми әдәби белем бирү барышында универсаль уку гамәлләре дүрт блокка бүлеп карала. Алар арасында **шәхси** УУГ − тормышчан, шәхескә юнәлтелгән, һөнәри юнәлештә үз юлын табуга, кешенең эчке потенциалын рациональ файдалана белүенә бәйле блок. Р**егулятив** уку гамәлләре шәхес тәрбияләүдә планлаштырырга өйрәтү, фаразлау, коррекция, бәяләү кебек якларны үзәккә ала. **Танып белү** гамәлен алгы планга чыгарган блокта логик, проблеманы кую һәм чишүгә юнәлтелгән, тамга-символик якны иңләгән гомум уку

гамәлләренә игътибар ителәә. **Коммуникатив** УУГ кешеләр язмышына битараф булмауны, кешеләргә ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләүне, иҗтимагый компетентлыкны үз эченә ала.

Федераль дәүләт стандартларына таянып, татар әдәбиятын өйрәнүнең **максаты** – туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес (гражданин) тәрбияләү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

– Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

– татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-типологик аспектта бирү;

– татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

– татар әдипләре, мәдәният әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, аңларга, башка халык сүз сәнгатен үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;

– татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү өчен, түбәндәге принциплар истә тотылырга тиеш. Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар әдәбиятының асылын төшендерү укытучының сүз сәнгате серләрен яхшы белүен, иҗади эшләү күнекмәләре булуын таләп итә. Мәктәп баласына сүз сәнгатенең серләрен ачуда **эстетик принцип** (укытучының матурлыкны күрә алуы һәм башкаларны да күрергә өйрәтә алуы), **эзлеклелек** (укучы алган белемнең тулыланып, баеп баруы), **әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнү** (татар телендә язылган әсәрләрдә әдәби образларны ачу үзенчәлекләре, татар теленең матурлыгын күрергә өйрәтү), күләме ягыннан кечкенә булган әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт булдыру, ягъни **психологик принцип** (мәктәп баласының яшь үзенчәлекләрен, әдәби әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып эш итү) ярдәмгә килә. Аерым игътибар **коммуникативлык принцибына** бирелә. Бу принципның өстен чыгуы рус телендә сөйләшүче укучыларның әдәби әсәр аша татар теленең серләренә тирәнрәк төшенүләре, матур әдәбият әсәрен сорауларга нигезләнеп сөйли алуы, үз фикерләрен ачык әйтә алуы, әдәби әсәрнең аралашу чарасына әверелүе белән дә бәйле. Укучыларның әдәби әсәрне кабул итү һәм әдәби үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, **дифференциацияләү** (аерым төркемнәргә аерып, бүлеп эшләү) һәм **интеграцияләү** (татар теле һәм рус әдәбияты дәресләрендә алынган теоретик белемнәрне һәм гамәли эш күнекмәләрен файдалану) дә үзәккә алына.

КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Дәрес темасы | Төп эчтәлек | Көтелгән нәтиҗә | | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты план / факт | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | метапредмет | предмет | шәхескә кагылышлы | | | |
| 1-2 | Хәтер катламнарындагы гәүһәрләр | Йола фольклоры | Йола фольклоры турында теорияне белү | Халкыбыз йолаларына гомуми күзәтү | Йолалар турындагы әсәрләр белән кызыксыну булдыру, сөйләмне алар ярдәмендә баету мөмкинлеген аңлау | “Халык авыз иҗаты” схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр, башка милләтләрнең халык авыз иҗаты белән чагыштырып, мисаллар китерү. | 4.09.-9.09.<br>4.09.-9.09. | |
| 3-4 | Гомернең гүзәл мизгелләре | Гаилә йолалары. Бәби туе. Туй | Укучыларга халкыбыз ның тарихы турында белем бирү | Йола фольклоры турында белешмә бирү; йолаларның төрләрен өйрәнү | Татар халык йолаларына, бәйрәмнәренә, халкыбызның үткәненә кызыксыну булдыру | “Халык авыз иҗаты” схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр, чылбыр буенча уку, чылбыр буенча сөйләү, җөмләләр төзү, проект эшенә әзерлек. | 11.09-16.09<br>11.09-16.09 | |
| 5-6 | Халкымның күңел бизәкләре | Фәтхи Бурнаш иҗаты. “Яшь йөрәкләр” драмасы | Халкыбыз йолаларына кызыксыну уяту | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, “Яшь йөрәкләр” әсәрен өйрәнү | Гореф-гадәт, йолаларга ихтирам тәрбияләү, аларны саклау; җыр-моңнарыбызга карата кызыксыну булдыру | Төркемнәрнең чыгыш ясавы, теоретик материал белән танышу. Сорауларга җавап эзләү, ишетеп аңлау, рольләргә бүлеп уку, әсәрдә автор әйтергә теләгән фикерне табу, әдәби әсәр турында фикер алышу | 18.09-23.09<br>18.09-23.09 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7-8 | Бәетләрдә халык язмышы | “Сак-Сок” бәете | Халык авыз иҗатын тарих белән бәйләп өйрәтү | Бәетләр турында белешмә бирү, “Сак-Сок ” бәетен өйрәнү | Борынгыдан килгән халык иҗатына хөрмәт һәм халык педагогикасы ярдәмендә ата-анага ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү | “Халык авыз иҗаты” схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр, чылбыр буенча уку, чылбыр буенча сөйләү, җөмләләр төзү. | 25.09-30.09<br>25.09-30.09 | |
| 9-10 | Шатлыгым, кайгым минем | Габдулла Тукай иҗаты. “Милли моңнар” шигыре | Шагыйрь яшәгән чор турында тарихи белешмә бирү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында өстәмә мәгълүмат бирү, “Милли моңнар” әсәрен өйрәнү | Татар халкының бөек әдипләре иҗатын өйрәнү аша тормышка караш булдыру | Җырлар тыңлау, ишетеп аңлау; яңа сүзләр белән эш, фронталь әңгәмә, дәреслек, дәфтәр белән эш, парлап сөйләшү – үз фикереңне әйтү, Интернеттан тарихи җырлар турында мәгълүмат табу. | 2.10-7.10<br>2.10-7.10 | |
| 11-12 | Асылташларга тиң хәзинәләр | Бүлекне кабатлау, йомгаклау. Контроль эш. | Халыкның йолаларга багышлан ган бай мирасын өйрәнү, әхлак һәм эстетик тәрбия бирү; белгәннәрне кирәк ситуациядә искә төшереп куллана белү | Йолаларны кабатлау, аның төрләргә бүленешенең принципларын истә калдыру | Халкыбыз мирасына ихтирам тәрбияләү, сөйләм культурасын үстерү | Төркемнәрнең чыгыш ясавы, теоретик материал белән танышу. Укылган әсәрләр турында фикер әйтү, кыскача эчтәлеген сөйләү, тест сорауларына җавап бирү, мөстәкыйль эш | 9.10-14.10<br>9.10-14.10 | |
| 13-14 | Милләтнең бриллиант кашлары | Фатих Әмирхан иҗаты. “Ай | Әдәбиятта фольклоризм | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә | Якыннарыңа, туганнарыңа ихтирам | Презентация ярдәмендә язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән | 16.10-21.10 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өстендә Зөһрә кыз” әкияте. Әдәбиятта фольклоризм. | турында теоретик төшенчә формалашты ру | бирү, “Ай өстендә Зөһрә кыз ” әсәрен өйрәнү | хисләре, мәрхәмәтлеле к тәрбияләү | танышу, “Әдәбиятта фольклоризм” төшенчәсен үзләштерү, төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, сәнгатьле уку. | 16.10-21.10 | |
| 15-16 | Үткер сүз, тапкыр сүз –уй бинасы | Нәкый Исәнбәт иҗаты. “Җирән чичән белән Карачәч сылу” драмасы | Театр сәнгате турында төшенчә формалашты Ру | Н.Исәнбәтнең тормыш юлы һәм иҗаты, фольлор өлкәсендәге эшчәнлеге турында белешмә; “Җирән чичән белән Карачәч сылу ” әсәрен өйрәнү | Әсәр аша ныклы ихтыяр көче тәрбияләү | Презентацияләр, өстәмә материаллар кулланып, язучының тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру; әсәргә җиңелчә әдәби анализ ясау; сораулар һәм биремнәр, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү, эчтәлек сөйли белү. | 23.10-28.10<br><br>23.10-28.10 | |
| 17-18 | Гаделлек барыбер җиңә | Г.Ибраһимов иҗаты. “Алмачуар” хикәясе | Язучы яшәгән чорга бәя бирү | Г.Ибраһимов ның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә; “Алмачуар ” әсәрен өйрәнү | Гаделлек, кешелеклелек сыйфатлары, хайваннарга карата мәхәббәт, миһербанлы лык хисләре тәрбияләү әсәр аша, татар халкы ның милли бәйрәмнәрен, йолаларын саклап калуның һәм дәвам итүнең әһәмиятен аңлату | Проект эшен яклап, төркемнәрнең чыгыш ясавы; яңа әсәр белән танышу, сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу, сораулар төзү, әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү, эчтәлек сөйли белү. | 6.11-11.11<br><br>6.11-11.11 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 19-20 | Милли киемгә мәдхия | Татар халкының милли киемнәре һәм бизәнү әйберләре | Милли сәнгать әсәрләре турында төшенчә бирү | Татар халкының милли киемнәре (түбәтәй, калфак, читек) һәм бизәнү әйберләре (беләзек, чулпы, изү) белән таныштыру | Милләтебезнең рухи мирасына ихтирам хисләре тәрбияләү | Г. Ибраһимовның “Алмачуар” әсәре буенча эшләнгән иҗади эшләрен карау, (презентация) чыгышларын тыңлау. Татар халкының милли киемнәре, бизәнү әйберләре белән танышу, төркемнәрдә эш, дәреслек, дәфтәрдә эш, презентация карау | 13.11-18.11<br>13.11-18.11 | |
| 21-22 | Кайгы җиле ишек какмасын | Роберт Миңнуллин иҗаты. “Килен төшкәндә” шигыре | Шигъри әсәрне җиңел истә калдыру ысулларын белү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә, “Килен төшкәндә ” әсәрен өйрәнү | Гореф-гадәтләргә, халкыбыз йолаларына ихтирам тәрбияләү | Язучының тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау, чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзү; сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, сәнгатьле уку | 20.11-25.11<br>20.11-25.11 | |
| 23-24 | Рөстәм Яхин моңнарының көче | Рөстәм Яхин иҗаты. | Җыр сәнгате турында белешмә бирү | Композитор Рөстәм Яхинның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, җырларын тыңлау | Музыка әсәрләре аша туган илгә, туган җиргә мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү | Композиторның тормыш юлы, иҗаты белән танышу; презентация карау, җырлар тыңлау, җыр сүзләрен тәрҗемә итү, истә калдыру. | 27.11-2.12<br>27.11-2.12 | |
| 25-26 | Кеше җирдә хаклы бәхеткә | Халисә Мөдәррисова иҗаты. “Көмеш дага” шигыре | Бөек Ватан сугышы турында тарихи мәгълүмат бирү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә; “Көмеш дага” әсәрен өйрәнү | Халкыбызның йолаларына кызыксыну булдыру, үткәннәребезгә ихтирам хисләре тәрбияләү | Язучының тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау; сәнгатьле уку, эчтәлек буенча фикер алышу; халык йолаларын искә төшерү, сүзлекчә белән эш | 4.12-9.12<br>4.12-9.12 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 27<br>-<br>28 | Халык авыз иҗатының әдәбиятта чагылышы | 2 нче бүлекне кабатлау дәресе Контроль эш. | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү | Өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау | Язучыларыбыз<br>ның фольклорны, халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын чагылдырган әсәрләргә кызыксыну уяту | Укылган әсәрләр турында фикер әйтү, кыскача эчтәлеген сөйләү, викторина сорауларына җавап бирү, мөстәкыйль эш | 11.12-16.12<br><br>11.12-16.12 | |
| 29<br>-<br>30 | Алар мәңге үлемсез | Әдип Маликов иҗаты. “Ил язмышы — ир язмышы” шигыре. Гражданлык лирикасы. Пафос. | Бөек Ватан сугышында катнашкан әдипләр турында тарихи мәгълүмат | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә, “Ил язмышы — ир язмышы” шигырен өйрәнү; Гражданлык лирикасы, пафос турындагы төшенчәләрне үзләштерү | Туган илгә мәхәббәт тәрбияләү | Бөек Ватан сугышы турында өстәмә материаллар белән танышу, презентация карау; шигырьне өлешләргә бүлү, бүлекләргә исем кую; сораулар, биремнәр үтәү, сәнгатьле уку, сүзлекчә белән эшләү; теоретик төшенчәләрне үзләштерү | 18.12-23.12<br><br>18.12-23.12 | |
| 31<br>-<br>32 | Без үлемсез туган ил белән | Гадел Кутуй иҗаты.“Сагыну” нәсере. Нәсер, инверсия. | Бөек Ватан сугышы чоры турында тарихи белешмә. | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә, “Сагыну” нәсерен өйрәнү; нәсер һәм инверсия турында төшенчә бирү | Туган илгә, халкыбыз батырлыгына ихтирам хисләре тәрбияләү | Язучының тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау; Бөек Ватан сугышында катнашкан язучылар иҗаты белән танышу; сәнгатьле уку, сүзлекчә белән эшләү; теоретик төшенчәләрне үзләштерү, өлешчә анализ ясау. | 25.12-30.12<br><br>25.12-30.12 | |
| 33<br>-<br>34 | Ил язмышы ирләр кулында | Сибгат Хәким иҗаты. “Бакчачылар” поэмасы | Хезмәт тәрбиясе бирү | Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә, | Хезмәт кешесенә карата ихтирам | Язучының тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау; Бөек Ватан | 8.01-13.01<br><br>8.01- | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | “Бакчачылар” поэмасын өйрәнү | тәрбияләү | сугышында катнашкан язучылар турында мәгълүмат бирү, һөнәрле булу турында әңгәмә; әсәр турында фикер әйтү, кыскача эчтәлеген сөйләү, сораулар төзү. | 13.01 | |
| 35 - 36 | Балачак хатирәләре | Рафаил Төхвәтуллин иҗаты. “Җиләкле аланнар ” повесте | Язучы яшәгән чорга тарихи күзәтү | Рафаил Төхфәтуллин иҗаты белән танышу, “Җиләкле аланнар” повестен уку | Өлкән буынга ихтирам, туган җиргә мәхәббәт тәрбияләү | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, төркемнәрдә фикер алышу; ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, хронологик таблица тутыру, план төзү. | 15.01-20.01<br><br>15.01-20.01 | |
| 37 – 38 | Сугыш язган язмышлар | Мөхәммәт Мәһдиев иҗаты. “Без — кырык беренче ел балалары” повесте. | Бөек Ватан сугышы чоры турында тарихи мәгълүмат | Мөхәммәт Мәһдиевнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат, “Без – кырык беренче ел балалары” повестеннан өзек белән танышу | Сугыш авырлыгын үз җилкәләрендә күтәргән яшь буынга, шул чор кешеләренә ихтирам тәрбияләү | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу; төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү, хронологик таблица тутыру, план төзү. | 22.01-27.01<br><br>22.01-27.01 | |
| 39 - 40 | Батырлар бар төштә – татарлар бар... | 3 нче бүлекне кабатлау дәресе. Мөстәкыйль эш. | Өйрәнгән материалны искә төшереп, гомумиләш тереп куллана белү | “Ил язмышы, ир язмышы” бүлегендә өйрәнгән материалны кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү | Патриотик тәрбия, туган илне, туган җирне яратырга өйрәтү | Төркемнәрдә эшләү, презентация карау, викторина сораулары, мөстәкыйль эш. | 29.01-3.02<br><br>29.01-3.02 | |
| 41 - 42 | Давыллы еллар җырчысы | Һади Такташ иҗаты. “Алсу” поэмасы. | 1920 – 1930 еллар турында | Һ. Такташ турында мәгълүмат, “Алсу” поэмасын уку | Татар шигъриятенә мәхәббәт уяту | Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация | 5.02-10.02 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | тарихи мәгълүмат | | | карау, хронологик таблица тутыру; парларда эшләү, шагыйрьнең тормышы турында сораулар төзү, җавап бирү; сүзлекчә белән эшләү, чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзү. | 5.02-10.02 | |
| 43-44-45-46 | Шигырьләрдә шагыйрь язмышы | Хәсән Туфан иҗаты. “Агыла да болыт агыла” шигыре | Репрессия еллары турында төшенчә | Хәсән Туфанның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә, “Агыла да болыт агыла” шигырен өйрәнү. Хафиз строфасы турында теоретик төшенчә | Туган илне сагыну хисләрен аңларга өйрәтү | Проект эшен яклап, төркемнәрнең чыгыш ясавы. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау, хронологик таблица тутыру; парларда эшләү, шагыйрьнең тормышы турында сораулар төзү, җавап бирү. Аудиоязмада җыр тыңлау, шигырьгә анализ ясау. Яңа теоретик төшенчәләр белән танышу. | 12.02-17.02<br>12.02-17.02<br>19.02-24.02<br>19.02-24.02 | |
| 47-48-49 | Чит җирләрдә йөртә язмышлар | Аяз Гыйләҗев иҗаты. “ Өч аршын җир” повесте | Тарихи вакыйгаларга нигезләнеп, әсәр геройлары яшәгән чорга характеристика | Аяз Гыйләҗев иҗаты белән танышу, “ Өч аршын җир ” повестеннан өзекләр уку | Геройларның яшәү кыйбласы аша нәтиҗәләр ясау һәм рухи сәламәтлек тәрбияләү | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу; төркемнәрдә фикер алышу, ишетеп аңлау, сүзлекчә белән эш, укыганны тәрҗемә итү, сораулар, биремнәр үтәү; хронологик таблица тутыру. | 26.02-3.03<br>26.02-3.03<br>12.03-17.03 | |
| 50-51 | Иленнән аерылган – канаты каерылган Ватан барыннан да | Илдар Юзеев “Ак калфагым төшердем | Әдәбият теориясе – ремарка | Илдар Юзеевның тормыш юлы, иҗаты белән | Туган җирнең изге булуын төшендерү, | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, хронологик | 12.03-17.03 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| -<br>52 | газиз | кулдан... "<br>драмасы.<br>Ремарка<br>5 нче бүлекне кабатлау.<br>Тест. | турында төшенчә | таныштыру; "Ак калфагым төшердем кулдан..." драмасын укып нәтиҗә ясау<br>Туган җирне ярату, туган як кадере, милләт язмышы, чит илләрдәге милләттәш ләребез турында аңлап калу | аның кадерен белергә өйрәтү<br>туган җиргә, милләттәшләр е<br>безгә ихтирам хисләре тәрбияләү | таблица тутыру; рольләргә бүлеп, сәнгатьле уку; сүзлекчә белән эшләү<br><br>Төркемнәрдә эшләү, викторина сораулары, мөстәкыйль эш. | 19.03-24.03<br><br>19.03-24.03 | |
| 53<br>-<br>54<br>-<br>55 | Балачак гомергә хәтердә калачак | Фатих Хөсни иҗаты.<br>"Сөйләнмәгән хикәя" әсәре.<br>Тема. | Язучы яшәгән чор турында тарихи белешмә | Фатих Хөснинең тормышы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, "Сөйләнмәгән хикәя" әсәрен өйрәнү, "тема" турында төшенчә формалаштыру | Җаваплылык хисе, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү | Презентация ярдәмендә язучы тормышы белән танышу, хронологик таблица тутыру, сәнгатьле уку; сүзлекчә белән эшләү, өлешләргә бүлү, исем кушу; эчтәлек сөйли белү. | 2.04-7.0<br><br>2.04-7.04<br><br>9.04-14.07 | |
| 56<br>-<br>57<br>-<br>58 | Гомерләрнең иң бәхетле көне | Роза Хафизова иҗаты. "Әти кайткан көн" хикәясе | Бөек Ватан сугышы елларындагы балалар язмышы турында төшенчә | "Әти кайткан көн" хикәясен уку, аңлау; автор Р.Хафизова турында мәгълүматлы булу. Идея турында төшенчә | Сугыш чоры балаларына карата ихтирамлы булырга өйрәтү | Дәреслек, дәфтәр белән эш; парлап сөйләшү, җөмләләр төзү, план төзү, укыганны гади җөмләләр белән кыскача сөйли белү. | 9.04-14.04<br><br>16.04-21.04<br><br>16.04-21.04 | |
| 59<br>- | Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт | Фәнис Яруллинның | Укыганны гомумиләште | Фәнис Яруллин иҗаты турында | Тәкәбберлекнең, дуслык кадерен | Язучының биографиясен кабатлау, | 23.04- | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 60-61 | | “Ак төнбоек” хикәясе | рә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү | кыскача белешмә, “Ак төнбоек” хикәясен укып нәтиҗә ясау | белмәүнең нинди куркыныч нәтиҗәләргә китергәнен аңлату, җаваплылык хисләре тәрбияләү | тест сорауларына җавап бирү; эчтәлек буенча төркемнәрдә фикер алышу, әсәргә җиңелчә әдәби анализ ясау, сораулар һәм биремнәр эшләү; әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү; план буенча гади җөмләләр белән сөйләү | 28.04<br><br>23.04-28.04<br>30.04-5.05 | |
| 62-63-64 | Тырышлык – зурлык, ялкаулык - хурлык | Рафис Корбан иҗаты “Ярдәм итик” шигыре | Бал кортлары һәм үләннәр турында табигать белеме фәненә бәйләп аңлату | Рафис Корбанның биографиясе белән танышу; “Ярдәм итик” шигырен уку | Тырышлык тәрбияләү, хезмәт яратырга өйрәтү | Проект эшен яклап, төркемнәрнең чыгыш ясавы. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты белән танышу, презентация карау, хронологик таблица тутыру, шигырьне тыңлау, ярымтавыш белән уку, чылбыр буенча уку, сайлап уку, яңа сүзләрне өйрәнү, парлап сөйләшү. | 30.04-5.05<br><br>7.05-12.05<br><br>7.05-12.05 | |
| 65-66-67 | Балачакның онытылмас мизгелләре | 6 нчы бүлекне кабатлау Контроль эш. | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү | Өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау | Язучылары бызның балачакның төрле мизгелләрен сурәтләгән әсәрләренә кызыксыну уяту | Язучыларның портретлары белән эш, викторина сорауларына төркемләп, парлап җавап эзләү; мөстәкыйль эш | 14.05-19.05<br><br>14.05-19.05<br><br>21.05-26.05 | |
| 68 | Каеннарның күз яше | Мөдәррис Әгъләмов иҗаты. “Сөйли | Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә | М.Әгъләмов ның тормыш юлы һәм иҗаты | Экологик тәрбия | Парлап сөйләшү, шигырьне тыңлап аңлау, ярымтавыш | 21.05-26.05 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ак каен...” шигыре | ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү | белән таныштыру; “Сөйли ак каен...” шигырен уку | | белән уку, чылбыр буенча сәнгатьле уку; эчтәлек буенча фикер алышу, шигырьгә анализ ясау, экологик проблемалар турында сөйләшү. | | |
| 69 – 70 | Әдәбият дигән дәрья... | Йомгаклау | Өйрәнгән теоретик төшенчәләр не кабатлау, истә калдыру | Ел буе өйрәнгәннәрне гомумиләште реп кабатлау | Әдәбиятның тәрбия бирү, тормышка әзерләү дәресе булуын аңлату | Портретлар, төрле иллюстрацияләр, презентацияләр ярдәмендә укылган әсәрләрне кабатлау, гомумиләштерү; сорауларга җавап бирү. | 28.05-31.05<br><br>28.05-31.05 | |

**Дәрестән тыш (өстәмә) уку өчен тәкъдим ителә торган әсәрләр**

(укытучы сайлавы буена)

Мостай Кәрим. Озын-озак балачак.
Нардуган (Татар халык йоласы) .
Покрау (Керәшен татарлары бәйрәме).
Уярня (Мари халык бәйрәме).
Ким Васин. Җыр шулай туды.
Әмирхан Еники. Җиз кыңгырау.
Юрий Семендер. Ике ветеран.
Гәрәй Рәхим. Буыннар елъязмасы.
Марс Шабаев. Күңелемә, эткәй, кайтып кер...
Нәҗип Думави. Габдулла.
Гөлшат Зәйнашева. Үз илемдә.
Фоат Садриев. Юкка көттеләр.
Айрат Суфиянов. Мәктәптән кайтып килеш.
Гавриил Троепольский. Акбай Караколак.
Зиннур Мансуров. Ятим Су анасы.
Гомәр Бәширов. Җидегән чишмә.
Шәйхи Маннур. Печән җыйганда.
Рашат Низами. Куркытылган поши.